| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2020 Баулы шәһәре № 141

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге, өченче затлар хокукыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләү һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында» 2019 елның 27 мартындагы 103нче карарына (2019 елның 16 октябрендәге 116 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15нче статьясы 3нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге, өченче затлар хокукыннан азат булган мөлкәт исемлегенә (Баулы шәһәр Советының 2019 елның 27 мартындагы 103 номерлы карары белән расланган (Баулы шәһәр Советының 2019 елның 16 октябрендәге 116 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны озак вакытка (шул исәптән ташламалы аренда түләве ставкалары буенча) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шулай ук түләүле нигездә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә бирү максатларында, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2нче һәм 3нче пунктларны төшереп калдырырга, 4нче һәм 5нче пунктларны 2нче һәм 3нче пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе

Р.Х. Гатиятуллин